СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №61 (7234) | 28 май, 1991 ел. СИШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

## Семинар үтте

Шимбә көнне «Кондырча» колхозында йон кырку, ясалма орлыкландыру, лагерьларның торышын карау буенча семинар үткәрелде. Семинарда йон кырку буенча технологлар, баш зоотехниклар, ветеринария врачлары, йон классификацияләүчеләр, токым эше белән шөгыльләнүчеләр, ревизия комиссиясе рәисләре катнашты.

«Кондырча» колхозының җәйге лагеренда терлекләрне җәйге чорда карау өчен барлык шартлар да тудырылган. Лагерь көтүлек янына урнашкан. Сөтүткәргеч кайнар су белән юдырыла, өченче ел инде 25 сыерга исәпләнгән тудыру бүлеге эшли, күп еллардан бирле йон кырку пункты эшли, пунктта сарыклар өчен кычыткан, башка үләннәр киптерү, күләгәдә йон киптерү мөмкинлекләре бар.

Семинарда катнашучылар барысын да карап, һәммәсе белән дә танышып чыктылар. Хуҗалыкның йон кырку остасы Илгизәр Тямаев 10 минут эчендә кырку үрнәге күрсәтте. Авыл хуҗалыгы идарәсе һәм хәзерләүләр конторасы белгечләре йон кыркучыларга һәм бу эштә катнашучыларга түләү, йонны квалификацияләү, йон буенча исәп-хисап эшләре һәм башкалар турында сөйләделәр. Семинарда катнашучылар җәйге лагерьны оештыру буенча шактый бай информация алдылар һәм тәҗрибә уртаклаштылар.



**ТАНЫШ БУЛЫГЫЗ:** рәсемдә «Москва» колхозы сыер савучысы Ирина Алексеевна Казакова. Ирина Алексеевна җәйләрен колхозда чөгендер игә, ә кыш көннәрендә Илюткино фермасында сыерлар сава. Һәр ике эшне дә җиренә җиткереп, намус белән башкарганга авылда хөрмәте зур аның.

## Кыңгыраулар сезгә бүген ак юл телиләр...

**Югары Норлат урта мәктәбендә дә соңгы кыңгырау чыңлады.**

**Беренче класс укучыларының чыгышы тантананы ачып җибәрде. Мәктәп директоры З. З. Яруллин, хуҗалыкның партоешма секретаре Р.Х. Шәйхетдинов, класс җитәкчесе Н. Т. Төхфәтуллина һәм башка укытучылар һәммәсе китүчеләргә хәер-фатиха бирделәр.**

**Бу тантананың рухын сезгә дә җиткерү өчен ата-аналар исеменнән чыгыш ясаган ФӘҮЗИЯ МӨХӘММӘТОВАның шигъри багышламасын газета укучыларыбызга тәкъдим итәбез.**

Соң мәртәбә бүген сезнең өчен
Көмеш кыңгырауның чыңлавы.
Кыңгырауда—саубуллашу чыңы,
Ямансудыр шуңа тыңлавы.
Ун ел үткән инде, һаман сезне
Нарасыйлар итеп тоябыз.
Канат җилпеп күктә очар өчен
Кысан инде туган оягыз.
Әниләрнең итәк чабуыннан
Нык ябышкан кулны каерып,
Язмыш сезне дөнья көтәр өчен
Китә инде бездән аерып.
Кай арада үсеп җиттегез соң?!
Күз тиярлек сылу, зифалар.
Саф күңелле ихлас җаныгызга
Кагылмасын явыз юхалар.
Рәхим-шәфкать сезнең янәшәдә
Иман нуры булып атласын.
Яманнарның явыз ниятеннән
Бер ходаем үзе сакласын.
Хыял дигән якты өметләрнең
Тормышларга ашып һәммәсе,
Юлыгыздан туры китә алсагыз,
Яшәүләрнең шунда мәгънәсе.
Торган җирең затлы сарай булып,
Кылганыгыз булсын изгелек,
Онытмагыз олы юлга илткән
Балачакның шушы мизгелен.
Торган җирең затлы сарай булып,
Баскычлары алтын булса да,
Тирә-юнең дан, дәрәҗә, шөһрәт,
Мал-мөлкәтләр белән тулса да,
Онытмагыз газиз туган җирнең
Җил-янгырын, бөркү-тузанын,
Туган якның җанга шифа биреп
Сулар һавасы да изге аның.
Онытмагыз, татлы сагыш белән
Бәхеттер ул яшәү сагынып,
Сагынганда бер ашкынып кайту
Кошлар кебек канат кагынып.
Туган якны изге ядкарь итеп
Хәтерләрдә мәңге саклагыз.
Олы юлга сезне озатабыз—
Өметләрне безнең аклагыз!!!

## Хыяллар чынга ашсын!

Алъяпкычың бүген ак икән
Ак булса да салыр чак
җиткән.

Әйе, унбер ел буена киеп йөргән ак алъяпкычларын салып шкафның арткы почмагына истәлек итеп кенә куяр чаклары җитте бу кызларның. Күпме шатлык, күпме моң бүген күңелләрдә. Унбер ел буена киңәшеп, ярдәмен сораган, шатлыклары, борчуларын уртаклашкан укытучылары, иптәшләре, дуслары бер парта артында утыручы, җан дустына әйләнергә өлгергән классташы белән аерылышу көтә аларны. Бүген Биккол мәктәбе укучылары өчен бирелгән соңгы кыңгырау тавышы нәкъ шул турыда соңгы тапкыр искәртә.

Элеккеге гадәт буенча укучылар бер-берсенә матур котлау сүзләре, ә укытучыларына исә шулар белән бергә олы рәхмәт хисләрен дә белдереп открыткалар бүләк итәләр. Ул гына түгел бәйрәм хуҗалары җырлар, моңсу шигырь юллары белән моны телдән дә җиткерәләр. Чәчәк бәйләменә күмелгән укучыларга һәр укытучы зур юлга чыгар алдыннан киңәшләрен биргәндә күз яшьләрен яшерүе бик кыен була. Быел да шундый ук бәйрәмдә булырга туры килде.

Бу класс белән аерылуы икеләтә моңсудыр, мәгаен. Күбәү булмасалар да мәктәптә уку буенча иң алдынгы класс алар. Белемгә омтылышлы, кызыксынучан, мавыгучан класс та шулар. Мәктәпнең үзешчән сәнгатендә алар тотка иде: класста ике укучының берсе үзе гармунда уйнап, үзе җырлый. Биредә биючеләр дә, курайчылар да бар. Музыка укытучысы Ринат Шаһиев җитәкчелегендә фольклор ансамбле хәтта Татарстан телевидениесеннән дә чыгыш ясады. Ансамбльдә укуда да иң алдынгылар Зөлфирә Гаязова, Әлфинә Мөхәммәдиева, Гүзәлия Шаһиева һәм башкалар катнаша. Авылда үткәрелгән барлык бәйрәмнәрдә дә клуб сәхнәсендә алар иде. Мәктәптә күпчелек очракта бу класс үрнәк итеп куела. Бу—вакытын белеп уйный да, көлә дә, җитди дә була белә торган класс.

Аңлашыла ки, мондый класстан аерыласы килми. Хәер, укытучылар да үкенерлек калдырмадылар. Булган белемнәрен, осталыкларын, күңел җылысын аларга бирергә тырыштылар.

Бәлки шуңадыр, соңгы вакытта җәмгыятебездә укытучы һөнәренең дәрәҗәсе төшү ягына баруга карамастан, күпчелек шул авыр һөнәрне сайларга теләк белдерәләр. Күңелдә өмет уянды: бәлки әле элеккечә укытучы сүзен зур хәрефләр белән яза торган вакыт җитәр. Шулай, зур өметләр баглана сезгә, укучылар! Ә бүгенгә җырдагыча:

Хыяллар—ак җилкән,
Кузгалырбыз иртән,
Ерак юлга чыгар
чак җиткән.
Ак юл сезгә, укучылар!

**Ф. ГАЛИМОВА.**
Биккол авылы.

### СЕЗ СОРАГАН ИДЕГЕЗ

## Бар мөмкинлектән файдаланып

**Газета укучылар кулларында булган талонга да азык-төлекне ала алмый интегүләре, озак вакыт чиратта торырга туры килүе, продукциянең бик аз сәүдә нокталарында реализацияләнүеннән зарланып редакциягә телдән һәм язма рәвештә дә мөрәҗәгать итәләр. Шушы уңайдан газета корреспонденты Р. АЙЗАТУЛЛИН халык депутатларының район Советы башкарма комитеты рәисе В. В. БОГАТИКОВ һәм райпо рәисе Һ. Х. САДЫЙКОВ белән очрашты һәм шәһәр хезмәт ияләрен азык-төлек белән тәэмин итүдә туган бу кыенлыкларның сәбәпләре, хәлне төзәтү чаралары турында сөйләүләрен үтенде.**

В. В. БОГАТИКОВ: Хезмәт ияләренең зары урынлы, нормалаштырылган товарны да теләгән вакытыңда барып ала алмыйсың. Ажиотаж шуннан башлана. Менә бер мисал. Он һәм ярмалар белән безне элеватор тәэмин итә. Майның 23 көнендә райпо һәм эшчеләрне тәэмин итү бүлекләре аркылы соңгы ике айның 28 меңнән артык он талоны реализацияләнде. ОРСлар аркылы шул ук вакытта 27 мең чамасы талонга шикәр, 24 мең талонга ярма җибәрелде. Халык аны алганда чиратлар хасил булды. Кызганычка каршы, бу һәм башка төр товарлар да даими булып тормый, шуңа халык чикләнгән күләмдә бирелгән азык-төлектән дә коры калудан шикләнә. Бу уңайдан шуны әйтергә кирәк, талон үзенең көчен югалтмый. Республика бу төр продукцияләрне мөмкинлекләреннән чыгып нормалаштырды һәм аны реализацияләүне гарантияли.

Хезмәт ияләре өчен товарларны барлык сәүдә нокталарында сатуны оештыруны сорап район Советы башкарма комитетына мөрәҗәгать итүчеләр дә байтак. Шәһәр халкына әлеге талоннарны реализацияләү буенча нигездә ОРСлар хезмәт күрсәтә: нефтьчеләр 14,5 мең, тимер юлчылар 5,0 мең, райпо 3,6 мең кешене продукция белән тәэмин итә. Талонга сатыла торган товарларны райпоның сәүдә нокталары аша күбрәк реализацияләү хакында республика җитәкчеләренә мөрәҗәгать иткән идек, ләкин бу бүленеш үзгәрешсез калды. Райпо авыл халкына хезмәт күрсәтәчәк. Әмма халык соравын исәпкә алып ОРСларның кибетләрен киңәйтү чараларын билгеләдек. Мисал өчен шикәр заводы поселогында нефтьчеләр ОРСының бер кибете ачыла. Тимер юл ОРСы талоннар реализацияләү буенча тагын ике сәүдә ноктасы булдыруны күздә тота. Спиртлы эчемлекләрне башка төр товарлардан аерып сату да чиратны киметүне күздә тота.

Һ. Х. САДЫЙКОВ: Владимир Васильевич китергән мисалдан райпо шәһәр халкына бик аз хезмәт күрсәтә булып күренә. Шуңа күрә бер нәрсәне күрсәтәсем килә: моннан тыш без «Зур гаилә», «Ветеран», «Диета» кибетләрен тиешле товар белән тәэмин итәбез.

Кайбер азык-төлек продуктлары, мәсәлән, үзебезнең азык комбинатында җитештерелгән печенье талонсыз да сатыла. Бу кондитер әйберләренә кытлыкны йомшартырга мөмкинлек бирә. Маргарин белән тәэмин итүдә өзеклек булмасын өчен аны Пермь өлкәсеннән китергәнне көтеп тормыйча үз транспортыбыз белән кайтарабыз.

Ләкин тулаем алганда, халыкны азык-төлек белән тәэмин итүдә туган кыенлык кимеми әле. Хәлне җиңеләйтү өчен бүленгән фондларның тулы алынуына, реализацияләнүенә ныклы контрольлек булдыру кирәк.

Бер үк вакытта горизонталь элемтәләрне арттыру юнәлешендә эшлибез. Районың дистәдән артык хезмәткәре промышленность, халык куллануы, азык-төлек товарларын өстәмә кайтару өчен гел юлларда булалар. Яңарак кына Кырымнан яшелчә консервлары кайтару турында килешенде. Ульяновск, Чабаксар шәһәрләреннән йөз меңнәрчә сумлык халык куллануы товарлары кайтару мөмкинлеге бар. Югары Норлаттан Ф. Хәбибуллин, Якты Күлдән Н. Гобәйдуллин, Киекледән М. Мостафин үзәкләштерелмәгән тәртиптә үз кибетләренә товарлар кайтаралар, халык ихтыяҗын мөмкин кадәр канәгатьләндерү өчен тырышалар. Бу алымны тагын да киң куллану, башка мөмкинлекләрне файдалану халыкның ихтыяҗын тәэмин итүне билгеле дәрәҗәдә яхшыртуга булышыр.

**Бүгенгә санда**

* *СОРАУЛАРГА ҖАВАПЛАР.
* *СОҢГЫ ЗВОНОК.
* *ПАТРИОТ.
* *БИКҮЛЕ ХӘБӘРЛӘРЕ.

# ТЕЛЕВИДЕНИЕ

**СИШӘМБЕ**
**28 МАЙ**
**КАЗАН КҮРСӘТӘ**

17.15 Мультфильмнар.
17.45 Казан шәһәренең 11 нче музыка мәктәбендә укучылар һәм укытучылар концерты.
18.30 «Нәтиҗә». Бәрәңге кыры ярдәм көтә.
19.00 «Татарстан».
19.30 «Әлли-бәлли-бәү».
19.40 ТССР Югары Советы сессиясендә.
21.40 Тапшырулар программасы.

**I ПРОГРАММА**

6.30 «Иртә».
9.00 «Актуаль репортаж».
9.20 В. Распутин. «Рудольфис». Фильм-спектакль.
10.35 Мультфильм.
11.00 «Балалар сәгате».
12.00 «ТЯХ».
12.15 «Позиция».
13.15 Л. Бермен уйный (фортепиано).
14.30 Документаль фильм.
15.00 «ТЯХ».
15.15 «Дәүләт чиге». 5 нче фильм. «Кырык беренче ел». 2 нче серия.
16.25 «Мавыгучылар дөньясы».
16.40 «Чемпионнар белән бергә».
16.55 Документаль фильм премьерасы.
17.45 «Балалар музыка клубы».
18.30 «Меридиан».
18.45 «Цхинвали балалары».
19.35 Н. Пейко. «Квинтет-вариация»
19.40 Кыска метражлы нәфис фильмнар премьерасы.
21.00 «Вакыт».
21.45 «ВиД» тәкъдим итә: «Могҗизалар кыры».
22.40 «Театр+ТВ».

**II ПРОГРАММА**

8.15 Документаль фильм премьерасы.
8.45 Балалар өчен фильм.
9.50 Мультфильм.
10.15 «Компьютер белән диалог».
11.00 С. Туликовның лирик җырлары.
11.30 «Меридиан».
13.15 «Хәбәрләр».
13.30 «Яшәгән, ди, өч юан». Нәфис фильм.
14.35 «Солдат мемуарлары». 3 нче фильм.
15.30 Ритмлы гимнастика.
21.45 РСФСР халык депутатларының IV съездында. Тәнәфестә—«Хәбәрләр».
23.45 СССР Югары Советы сессиясендә.

**ЧӘРШӘМБЕ**
**29 МАЙ**
**КАЗАН КҮРСӘТӘ**

17.25 Композитор М.Яруллин бездә кунакта.
18.00 «Ватандашларым минем...»
18.25 Халык предприятиесе. Нәрсә ул? (КЭМЗ. Хосусыйлаштыру тәҗрибәсе).
19.00 «Татарстан».
19.30 Футбол. Европа чемпионатына сайлап алу матчы.
20.15 «Тыныч йокы, нәниләр».
20.30 «Әлли-бәлли-бәү».
21.10 «Баянчылар кунакханәсе». Баянчылар А.Кәримов һәм Ш. Нуриев бездә кунакта.
21.35 Реклама.

**I ПРОГРАММА**

6.30 «Иртә».
9.00 «Эшлекле курьер».
9.20 «Пируэт»—Свердловскидан».
10.35 «Балалар музыка клубы».
10.50 Кыска метражлы нәфис фильмнар.
12.00 «ТЯХ».
12.15 «Театр+ТВ».
15.00 «ТЯХ».
15.15 «Чүлдәге гаҗәеп пейзаж». Нәфис фильм.
16.20 «Мавыгучылар дөньясы».
16.35 «Калинка» рус халык инструментлары ансамбле концерты.
16.55 «Балалар сәгате» (инглиз теле дәресе белән).
17.55 «9 нчы студия».
18.55 Мультфильмнар.
19.30 Концерт.
20.00 РСФСР Президенты постына кандидатлар тәкъдим итәбез.
21.00 «Вакыт».
21.45 Теннис. Франциянең ачык чемпионаты.
22.05 Футбол. Европа чемпионнары кубогы. Финал. Тәнәфестә—Теннис. Франциянең ачык чемпионаты.

**II ПРОГРАММА**

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.15 Фәнни-популяр фильм.
8.35 Фильм-концерт.
9.05 Балалар өчен фильм.
10.10 Лев Лещенко концерты.
11.10 Мультфильм.
11.30 «Ничек яшисең, Россия». Документаль фильм.
12.40 «С» бригадасы».
13.20 Телефильм.
13.30 «Яшәгән, ди, өч юан». Нәфис фильм.
14.35 Концерт.
15.15 «Манера».
17.00 «Самагарт». Самараның яшь шагыйрьләре.
21.45 СССР Югары Советы сессиясендә.
22.45 «Коллаж».
22.50 «Хәбәрләр».
23.05 «Минем чегәннәрем».
Нәфис фильм.

**ПӘНҖЕШӘМБЕ**
**30 МАЙ**
**КАЗАН КҮРСӘТӘ**

17.25 «Синең туган—минем туган». Нәфис фильм.
18.40 «Иң матур җыр». Балалар җырлары конкурсы йомгаклары.
19.00 «Татарстан».
19.30 «Актуаль интервью». «Тел һәм безнең киләчәгебез». Тапшыруда «Мәгариф» журналының баш редакторы Ф. Шәрифуллин катнаша (татар телендә).
19.45 «Әлли-бәлли-бәү».
19.50 «Телесеанс». Яшьләр программасы.
20.45 Реклама.
20.55 Тапшырулар программасы.

**I ПРОГРАММА**

6.30 «Иртә».
9.00 «МВД белешмәләре буенча».
9.20 Футбол. Европа чемпионатына сайлап алу матчы. СССР—Кипр җыелма командалары. 2 нче тайм.
10.10 «Чемпионнар белән бергә».
10.25 Мультфильм.
10.35 Документаль фильм.
11.00 «Балалар сәгате».
12.00 «ТЯХ.
15.15 «Иван». Нәфис фильм.
16.25 «Мавыгучылар дөньясы».
16.40 «Әни, әти һәм мин».
17.10 Документаль фильм.
18.10 «Рококо».
18.30 «Меридиан».
18.45 «... уналтыга кадәр һәм өлкәнрәк».
19.30 «Реликт» вокаль триосы чыгышы.
19.50 Нәфис фильм премьерасы. «Даладагы ату».
21.00 «Вакыт».
21.45 «МВД белешмәләре буенча».
22.00 «Эфирда музыка».

**II ПРОГРАММА**

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.15 Документаль фильм премьерасы.
8.40 Н. Чепрага җырлый.
9.05 Балалар өчен фильм.
10.10 Б. Туманян катнашында концерт.
10.50 «Отрядтагы гыйбадәтханә».
11.30 «Совершенно секретно» газетасы таныштыруы.
13.00 «Александр Солженицын сүзе».
13.30 «Ирләр дуслыгы». Нәфис фильм.
14.35 «Лонго Май—озак яшә». 1 нче тапшыру.
15.10 «Экранда 01 хезмәте».
23.15 Концерт.
23.45 «Өяз тормышындагы кайбер нәрсәләр». Нәфис фильм.

**ҖОМГА**
**31 МАЙ**
**КАЗАН КҮРСӘТӘ**

17.05 «Күрелмәгән гасыр башы». Нәфис фильм.
18.20 «Редакциягә хат килде». Тележурнал.
19.00 «Татарстан».
19.30 «Җомга көн кич белән». Альманах.
20.15 «Тыныч йокы, нәниләр».
20.30 «Әлли-бәлли-бәү!.
21.20 «Гримсыз гына». Телевизион фильм.
20.40 Эстрада концерты.
21.40 Тапшырулар программасы.

**I ПРОГРАММА**

6.30 «Иртә».
9.00 Г. Телеман. Си бемоль мажор сюитасы.
9.30 Документаль фильм.
10.10 «...уналтыга кадәр һәм өлкәнрәк».
10.55 «Даладагы ату». Нәфис фильм.
12.00 «ТЯХ».
15.15. Нәфис фильм.
16.25 «Мавыгучылар дөньясы».
16.40 Рус җырлары ансамбле концерты.
17.05 «Җинүчеләр» тапшыруы сәхифәләреннән.
18.30 «Меридиан».
18.45 Мультфильмнар.
19.20 Концерт.
20.00 РСФСР Президенты постына кандидатлар тәкъдим итәбез.
21.45 «ВиД» тәкъдим итә: «Дело», «Шоу-биржа», «Музобоз», МТВ.
21.00 «Вакыт».
00.00 «ТЯХ».

**II ПРОГРАММА**

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.15 Документаль фильм премьерасы.
9.10 Балалар өчен фильм.
10.15 «Музыкаль телеабонемент».
11.15 Мультфильм.
11.30 Документаль фильм.
12.00 «Миссис СССР—миссис Америка». Конкурс.
13.30 «Мәхәббәт гафу итми». Нәфис фильм.
14.35 А. Дольский җырлый.
15.05 «Лонго Май—озак яшә». 2 нче тапшыру.
21.45 Классик музыка концерты.
22.00 «Матбугат ложасы».
23.00 «Хәбәрләр».
23.15 Нью-Йорк университеты профессоры Александр Янов белән очрашу.
23.50 Волейбол. Дөнья лигасы беренчелеге. Ирләр СССР—Япония җыелма командалары.

## Владимир Георгиевич МЕДВЕДСКИЙ

24 майда 77 нче яшендә җирле билгеләмәдәге персональ пенсионер, ике «Почет Билгесе», Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары кавалеры һәм бик күп медальләр хуҗасы, Норлат шикәр заводының беренче директоры 1949 елдан КПСС члены ВЛАДИМИР ГЕОРГИЕВИЧ МЕДВЕДСКИЙ вафат булды.

В. Г. Медведский 1914 елның 25 октябрендә Украина ССРның Винница өлкәсе Ямполь районы Тростянец авылында эшче гаиләсендә туган. Ул үзенең хезмәт юлын 1928 елда Гоноровск шикәр заводында өйрәнчек слесарь булып башлый. 1938 елда, шикәр-рафинад промышленностеның Одесса механика-технологик техникумын тәмамлагач, Медведский Киев өлкәсенең Смола шәһәре шикәр-рафинад заводында мастерской мөдире булып эшли.

Владимир Георгиевич 1941 елдан алып 1956 елга кадәр Куйбышев өлкәсенең Тимашев шикәр комбинатында җылылык ТЭЦы начальнигы, директор булып эшли. 1956 елдан алып иптәш Медведский безнең Норлат шикәр заводын үстерүгә бөтен көчен, белемен, тәҗрибәсен бирә. Бу җаваплы постта Владимир Георгиевич зур энергия, максатчанлык белән хезмәт итте. Аңа югары таләпчәнлек, эшлеклелек, принципиальлек һәм оештыру сәгалыгы, кешеләр турында даими кайгыртучанлык хас иде. Ул шикәрчеләр поселогының социаль-культура йөзен үзгәртүгә зур әһәмият бирде.

Тирән ихтирамлы, ягымлы кеше буларак, ул барлык коммунистларның, завод хезмәтчәннәренең, шәһәр һәм район халкының ихтирамын казанды. Иптәш Медведский КПССның Октябрь райкомына член, район Советына депутат итеп берничә кат сайланды. Аның хезмәтләре Ватан бүләкләре белән билгеләп үтелде.

1974 елда В. Г. Медведский лаеклы ялга чыкты, ләкин үзенең туган заводы белән элемтәне гомеренең соңгы көннәренә кадәр өзмәде. Ул завод ветераннары советының актив члены иде. Озак вакытлар буе халык контроле группасына җитәкчелек итте, яшь белгечләр остазы иде.

Кеше, коммунист, намуслы, ярдәмчел, тыйнак иптәш В. Г. Медведский истәлеге безнең йөрәкләрдә озак сакланыр.

**Х. Х. Морадыймов, Ә. В. Мөлеков, А. А. Коростелев, В. В. Богатиков, Ф. Ш. Галимов, В. В. Иванов, Л. Н. Газизуллина, Х. Х. Гатин, А. П. Шамкин, Т. А. Назарова, Ю. В. Терентьев, Ә. Н. Миназов, Р. С. Чахчев, Ф. М. Галимов, Г. К. Пакшин, И. И. Петров, Г. К. Гыйматдинов, Ә. И. Сөләйманов, Ш. В. Кашапов, Л. Н. Горшенина, Л. Н. Соколова, В. И. Миронов, В. Е. Якшин.**



Японияңең Кагава префектурасында үткәрелгән кабак үстерү чемпионатында 42 яшьлек Сиодзи Сираи чемпион булды. Узган җәйдә ул 199,2 килограмм авырлыгындагы кабак үстерде. Ярышта барлыгы Япониянең 18 префектурасыннан 183 кеше катнашты.

Рәсемдә: чемпион үзенең «рекорды» белән.

КИОДО—ТАСС фотосы.

## Укыдыгызмы, ишеттегезме?

Көлү—артерияләр һәм эчәкләр «гимнастика»сы һәм бит өчен табигый массаж гына түгел, ул йокысызлыктан арындыручы да, хәтта кайбер очракларда астманы дәвалаучы да.

Шулай итеп, көлегез! Шөкер, көләр нәрсәләр бездә җитәрлек...

x x x

Сатып алучыларны алдау нәтиҗәсендә хөкүмәткә ел саен 10,7 млрд. сум зыян килә.

x x x

Торак-коммуналь хуҗалыкта һәм хезмәт күрсәтүдә заказчыларны алдау һәм алардан акча кысу нәтиҗәсендә килгән зыян 2,6 млрд. сум.

x x x

Дәүләт сәүдәсеннән алынган алкогольле эчемлекләр белән яшертен сату итү безнең кесәдән тагын 100 млн. сумны суырып чыгара.

«Күләгәдәге» экономикага китә торган сумманың гомуми күләме—60 млрд. сум.

**МӨХӘРРИР Ә. У. АБДУЛЛИН.**

Учредительләр— халык депутатларының Октябрь район Советы, КПССның партия оешмасы.

Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.

**РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ:** 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.
**ТЕЛЕФОННАР:** мөхәррир—2—12—14, 2—22—81, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары—2—15—63, социаль-экономика бүлеге— 2—22—51, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.

Газетаны Фидания ХӘЙРЕТДИНОВА җыйды. Асия МОРАТХАНОВА верстка ясады. Фирдания ХУЗЯХМЕТОВА басты. Корректор—Зөлфия ВӘЛИЕВА.

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.
Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.
Күләме—1 басма табак. Заказ 61. Тираж 3411.